**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2026 елның 2 марты 21-РС номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә хакында»Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 26 июнендәге 35-РС номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Лаеш муниципаль районы территориясендә хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкны үстерү максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставының 32 пунктының 1 өлешенәдәге 29 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 26 июнендәге 35-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

«район Башкарма комитетының төп бурычлары һәм вәкаләтләре» 3 бүлегенең 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлек өстәргә:

«10) хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкны үстерү максатларында:

«-хезмәт өлкәсендә социаль партнерлык системасын үстерүне һәм район җирле үзидарә органнарының профсоюзлар (профсоюзлар берләшмәләре), эш бирүчеләр (эш бирүчеләр берләшмәләре) белән, хезмәт законнары нигезендә әлеге органнар эшчәнлеге өлкәсендә социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аларга бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итә;

– социаль-хезмәт һәм аларга турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә социаль партнерлык принципларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

– районда социаль партнерлык мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге районның рәсми сайтында мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

– районның социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өч яклы территория комиссиясе (алга таба – территория комиссиясе)эшчәнлеген тәэмин итә;

– район җирле үзидарә органнарының хезмәт һәм аларга турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлары проектларын район Советына кертелгәнче яисә алар буенча район җирле үзидарә органнары карарлар кабул иткәнче территория комиссиясе утырышларында карауны тәэмин итә;

– территория комиссиясе карарларын район Советына җиткерүне һәм районның җирле үзидарә органнары тарафыннан каралуны, ә җайга салынмаган каршылыклар булганда – территория комиссиясенә җибәрелгән хезмәт өлкәсендәге норматив хокукый актлар проектларына карата аның якларының фикерләрен район Советына җиткерүне һәм районның җирле үзидарә органнары тарафыннан каралуны тәэмин итә;

– Профсоюзлар (профсоюзлар берләшмәләре), эш бирүчеләр (эш бирүчеләр берләшмәләре) белән социаль-хезмәт һәм аларга турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар проектларын социаль партнерлык кысаларында килештерүне тәэмин итә;

– профсоюз ягы вәкилләрен һәм эш бирүчеләрдән якларны Башкарма комитет тарафыннан төзелә торган социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча комиссияләр, эшче төркемнәр, Советлар составына кертүне һәм аларның эшендә катнашуны гамәлгә ашыра.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Т. Гарифуллинга йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**